Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Мичурин авыл җирлегенең
Яңа Сережкино авылыгражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино авылыгражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге Яңа Сережкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәреннән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Сережкино авылындагы Лесная урамындагы авыл эчендәге юллардагы чокырларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ» соравы буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 263 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 137.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 98 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Яңа Сережкино авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлеге составына керүче Мичурин торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Мичурин авыл җирлеге Яңа Сережкино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары тол хатыннары,

тыл хезмәтчәннәреннән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
-
- - Яңа Сережкино авылындагы Лесная урамындагы авыл эчендәге юллардагы чокырларны ремонтлау;
- - Яңа Сережкино авылы юлларын кардан чистарту сораулары буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт - мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 – авыл мәдәният йорты бинасы, Үзәк урам, 15 йорт – мәктәп бинасы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Иванова